# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

Бњлек ______________________________________

Автор ______________________________________

Дата ______________________________________

Кем эшкђртте ____________________ Бњлек мљдире ______________

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 24 апрелендә теркәлде, №2710

Татарстан Республикасы Мәагриф һәм фән министрлыгы

Боерык

13.04.2015 Казан ш. №4640/15

"Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары" дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесен үткәрү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 24 апрель, 2013 ел, №1595/13 боерыгы белән расланган "Мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт шартларын һәм хезмәтләрен саклауны яхшырту, Мәгариф учреждениеләренең иминлеге" 2013/2015 елларга Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының тармак программасын тормышка ашыру, шулай ук үсеп килүче буын арасында хезмәт иминлеген һәм хезмәтне саклауны пропагандалау, шәхси иминлек һәм тирәсендәгеләрнең иминлеге мәсьәләләренә карата аңлы һәм җаваплы мөнәсәбәтне формалаштыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 2 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

1. 2015 елның 27 апреленнән 2015 елның 11 июненә кадәр ике этапта “Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесен үткәрергә:

1.1. I этап – 2015 елның 27 апреленнән 28 майга кадәр – муниципаль дәрәҗәдә һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында;

1.2. II этап – 2015 елның 4 июненнән 14 июньгә кадәр – республика дәрәҗәсендә, бәйгенең I этабында җиңүчеләр арасында.

2. Расларга (кушымта итеп бирелә):

“Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесен үткәрү турында нигезләмәне (№1 кушымта);

“Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесе комиссиясе составын (№2 кушымта);

“Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесенә йомгак ясауга чыгымнар сметасын (№3 кушымта).

3. Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары мәгариф бүлекләре (идарәләр) җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 3 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

фән министрлыгы карамагындагы югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

Бәйгенең I этабын оештыру һәм үткәрү буенча ведомство (бәйге) комиссияләрен (алга таба – ведомство (бәйге) комиссияләре) булдырып расларга;

мәгариф оешмаларында укучылар арасында бәйгенең I этабын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Ведомство (бәйге) комиссияләренә бәйге шартларын үтәүне һәм бәйгенең I этабын үткәрү йомгаклары буенча иң яхшы хезмәтләрне үз вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары А.М.Каюмовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.Фәттахов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.04.2015 ел, №4640/15 боерыгына

№ 1 кушымта

“Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесен үткәрү турында нигезләмә

Гомуми нигезләмәләр



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 4 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35

1.1. “Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесе (алга таба – Бәйге) үсеп килүче буын арасында хезмәт иминлеген һәм хезмәтне саклауны пропагандалау, шәхси иминлек һәм тирәсендәгеләрнең иминлеге мәсьәләләренә карата аңлы һәм җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру максатыннан чыгып үткәрелә.

1.2. Бәйге ирекле нигезендә түбәндәге номинацияләр буенча уздырыла:

1.2.1. “Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага иң яхшы рәсем.

1.2.2. “Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага иң яхшы инша.

2. Бәйгене оештыру һәм үткәрү

2.1. Бәйгедә катнашырга мөмкин:

– мәктәпкәчә белем бирүче оешмаларның әзерлек төркеменә йөрүче балалар;

– гомуми белем бирү оешмаларында укучылар;

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри мәгариф оешмаларында белем алучылар.

2.2. Бәйге үткәрелә:

“Иң яхшы рәсем” номинациясендә:

– мәктәпкәчә белем бирүче оешмаларның әзерлек төркемнәренә йөрүчеләр арасында;



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 5 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35

– гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары арасында;

– гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучылары арасында;

– югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучылар арасында.

“Иң яхшы инша” номинациясендә:

– гомуми белем бирү оешмаларының 5-7 сыйныф укучылары арасында;

– гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында;

– югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучылар арасында.

2.3. Бәйге ике этапта үткәрелә

I этап – муниципаль дәрәҗәдә һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында, һөнәри мәгариф оешмаларында;

II этап – республика дәрәҗәсендә муниципаль дәрәҗәдә җиңүчеләр, югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри мәгариф оешмалары арасында.

2.4. Бәйгенең I этабын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләр) җитәкчеләре һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри мәгариф оешмалары җитәкчеләре тарафыннан Бәйгенең I этабын үткәрү турында боерык чыгарыла, ведомство (бәйге комиссиясе составы һәм аның эш тәртибе раслана.



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 6 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Ведомство (бәйге) комиссиясе мәгариф идарәсе органнары, профсоюз оешмасы вәкилләреннән формалаштырыла. Ведомство (бәйге) комиссиясе составына җирле үзидарә һәм дәүләт күзәтчелеге органнары вәкилләре, хезмәтне саклау өлкәсендә белгечләр (шул исәптән чит оешмалар белгечләре) һәм кызыксынулы булмаган башка затлар кертелергә мөмкин.

Бәйгене үткәрү, аны үткәрү сроклары һәм шартлары турында мәгълүмат Бәйгенең I этабын оештыручылар тарафыннан ведомство карамагындагы мәгариф оешмаларына җибәрелә. Мәгариф оешмалары җитәкчеләре укучыларга Бәйге үткәрелү турында хәбәр итүне оештыра.

2.5. Бу нигезләмә таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән бәйге өчен хезмәтләр укучылар тарафыннан үзләре белем ала торган оешманың педагогик хезмәткәренә 2015 елның 18 маена кадәр тапшырыла.

2.6. Педагогик хезмәткәр, бәйге өчен хезмәт Бәйгедә катнашуның барлык таләпләре һәм шартларына туры килгән очракта, бәйге өчен хезмәткә заявка булдыра.

Заявка басма рәвештә А6 форматындагы биттә тутырыла һәм бәйге өчен хезмәтнең беренче битенә югарыгы уң почмагына беркетеп куела. Заявка Бәйгенең I һәм II этаплары дәвамында бәйге өчен хезмәттән алынмый, заявкада түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

– бу нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә номинация атамасы һәм бәйгедә катнашучының яшь категориясе;

– хезмәт авторының фамилиясе, исеме һәм яше, сыйныфы, төркем, курсы, адресы (почта индексын күрсәтеп);



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 7 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

– педагогик хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтәгә керү өчен телефоны;

– мәгариф оешмасының тулы рәсми атамасы, адресы (почта индексы белән), җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме.

2.7. Бәйгенең I этабында 2015 елның 19 маеннан 21 маена кадәрге срокта заявкалар һәм бәйге өчен хезмәтләр – бу нигезләмәнең 2.2. пунктында күрсәтелгән яшь категориясендә һәр номинация буенча иң яхшы рәсемнәр һәм иншаларны җибәрелә:

мәктәпкәчә мәгариф оешмалары, гомуми белем бирү оешмалары территориаль ведомство (бәйге) комиссиясенә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри мәгариф ое шмалары уку урыны буенча ведомство (бәйге) комиссиясенә.

2.8. Ведомство (бәйге) комиссиясе 2015 елның 22 маеннан 28 маена кадәрге срокта кабул итеп алынган материалларны карап тикшерә, Бәйгенең I этабында катнашучыларның иң яхшы хезмәтләрен бу нигезләмәнең 4-6 бүлекләре таләпләренә туры килүен билгели һәм күрсәтелгән яшь категорияләре буенча һәр номинациядә призлы урыннар бирә.

Ведомство (бәйге) комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

2.9. Муниципаль мәгариф бүлекләре (идарәләр) җитәкчеләре, шулай ук югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары ведомство (бәйге) комиссиясе беркетмәсе нигезендә Бәйгенең I этабы йомгаклары турында боерык чыгара, боерык өч көнлек срок эчендә


Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 8 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35

Бәйгедә катнашучыларга электрон документлар әйләнеше системасы аша җибәрү яки мәгариф оешмасының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру нигезендә җиткерелә.

2.10. Беренче урынны алган Бәйгенең беренче этабында катнашучылар хезмәтләре Бәйгенең II этабында катнашуга тәкъдим ителә.

Муниципаль мәгариф бүлекләре (идарәләр) ведомство (бәйге) комиссияләре һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри мәгариф оешмалары 2015 елның 29 маеннан 3 июненә кадәрге срокта республика комиссиясенә I урынны яулаган Бәйгенең I этабы йомгаклары буенча җиңүчеләр турында мәгълүматлар тапшыра:

– Бәйгенең I этабы йомгаклары турында җитәкче боерыгын;

– Бәйгенең I этабына йомгак ясау буенча ведомство (бәйге) комиссиясе утырышы беркетмәсен (комиссия утырышы беркетмәсендә Бәйгедә катнашкан барлык укучыларның саны турында мәгълүмат булырга тиеш), беркетмәдә ведомство (бәйге) комиссиясе рәисе һәм әгъзаларының имзалары булырга тиеш.

– Бәйгенең I этабы призерлары турында ведомство (бәйге) комиссиясе карары, карар ведомство (бәйге) комиссиясе рәисе һәм әгъзаларының имзалары белән расланырга тиеш;

– оешмаларның күрсәтелгән төрләре һәм яшь категорияләре буенча "Иң яхшы рәсем" һәм "Иң яхшы инша" номинацияләрендә I урынны алуга ирешкән җиңүчеләрнең бәйге өчен хезмәтләрен (заявка белән бергә).



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 9 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Республика комиссиясе составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

2.11. Республика комиссиясе 2015 елның 4 июненнән 11 июньгә кадәрге срокта ведомство (бәйге) комиссияләре тарафыннан тапшырылган бәйге өчен хезмәтләрне карап тикшерә, бу нигезләмәнең 4-6 бүлекләре таләпләренә туры китереп, тапшырылган материаллар буенча Бәйгенең II этабы призерларын билгели.

Бәйгедә җиңүчеләр һәм призерлар турында республика комиссиясенең йомгак карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, республика комиссиясе әгъзаларының имзалары белән раслана һәм республика комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

2.12. Республика комиссиясе карары нигезендә бәйге йомгаклары турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы чыгарыла.

Бәйге йомгаклары турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы боерыкка имза салынганнан соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгың рәсми сайтына урнаштырыла.

Бәйге нәтиҗәләре дә Бәйге үткәрүгә җәлеп ителгән муниципаль мәгариф бүлекләренә (идарәләр) һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы мәгариф оешмаларына "Электрон Татарстан" электрон документлар әйләнеше системасы аша җибәрү юлы белән җиткерелә.



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 10 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

2.13. Бәйге тәмамланганнан соң Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелгән барлык бәйге өчен хезмәтләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары муниципаль мәгариф бүлекләренә (идарә) һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы мәгариф оешмаларына экспозиция эшчәнлегендә куллануга тапшырыла. Бәйге өчен хезмәтләрне саклауга, аларның сакланылышына шулай ук башка бәйгеләрдә кулланылышына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җавап бирми.

3. Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү

3.1. Бәйгенең I этабында җиңүчеләр дипломнар (грамоталар), шулай ук, Бәйгенең I этабын оештыручылар теләге мөмкинлегенә карап, призлар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә. Бәйгенең I этабына эчтәлекле, үзенчәлекле материаллар тапшырган, әмма призлы урыннарны алмаган Бәйгедә катнашучылар “Актив катнашкан өчен” дипломнар (грамота) белән бүлкәләнә.

3.2. Бәйгенең II этабында һәр номинациядә җиңүчеләр дипломнар (грамота) һәм призлар белән бүләкләнә.

3.3. Бәйге җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләр грамоталар белән бүлкәләнә.

4. Бәйге өчен хезмәтләрнең темасы



Документ создан в электронной форме. № 6440/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 11 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Барлык яшь категорияләре өчен инша һәм рәсемнәрнең бәйге хезмәтләре гомуми темасы – “Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары”.

Хезмәтләрдә түбәндәге мәгълүматларны чагылдыру тәкъдим ителә:

укучының “хезмәтне саклау” төшенчәсен үзенчә ничек аңлавы, имин хезмәт һәм мәгариф процессын оештыру;

хезмәтне саклау таләпләренең үтәлмәве аркасында хезмәткәрләрнең тормышы һәм сәламәтлегенә ихтимал янаулар;

үсеп килүче буында шәхси иминлек һәм тирәсендәгеләрнең иминлеге, иминлек техникасы кагыйдәләрен үтәмәүнең аянычлы нәтиҗәләре мәсьәләләренә карата аңлы һәм җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру зарурилыгы;

белем бирү оешмасында көнкүрештә, урамда, дәресләрдә һәм тәнәфесләрдә, төрле чаралар (хезмәткә өйрәтү) юл хәрәкәте кагыйдәләре, янгын куркынычсызлыгы, электр иминлеге буенча дәресләр һ.б.) үткәргәндә төп иминлек кагыйдәләре белән таныштыруның ни рәвешле хәл ителүе;

махсус кием-салым һәм башка индивидуаль саклану чараларын куллану нигезендә, төрел һөнәр кешеләренең хезмәте;

минем киләчәктәге һөнәремнең хезмәт куркынычсызлыгы буенча аерым белемнәр һәм күнекмәләр таләп итүе;

махсус кием-салым һәм башка саклану чараларын кулланып, эшләү процессында төрле һөнәрләр һәм белгечлекләр;

төрле һөнәрләр өчен хәвеф-хәтәрсез эшләргә өндәү-чакырулар;



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 12 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

өйдә, урамнарда һәм юлларда, балалар бакчаларында, мәктәптә, җәйге ялда үз-үзеңне имин тоту;

мәктәп укучысының хезмәтен саклау: информатика, физкультура, хезмәт, физика һәм химия дәресләрендә эшләү иминлеге;

ата-аналарның хезмәтен саклау.

5. Хезмәтләргә карата таләпләр

5.1. Бәйге предметы булып рәсемнәр һәм иншалар тора.

5.2. Бәйге өчен хезмәтләр, авторы тарафыннан, хезмәтнең югаргы сул почмагында үз кулы белән имзаланган булырга тиеш, хезмәт авторының фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшен сыйныфын (төркем) курсын, Бәйгегә хезмәтне тәкъдим иткән мәгариф оешмасы атамасын һәм адресын, педагогик хезмәткәрнең ФИО, хезмәт авторының һәм педагогик хезмәткәрнең элемтәгә керү өчен телефонын күрсәтеп.

5.3. "Интернет" мәгълүмат-коммуникация челтәреннән алынган, массакүләм мәгълүмат чараларында элегрәк басылып чыккан һәм шундый ук башка бәйгеләрдә катнашуга кабул ителгән хезмәтләр (рәсемнәр һәм иншалар) Бәйгегә кертелми. Хезмәтләр эчтәлеге игълан ителгән темага һәм бәйгедә катнашучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә тиеш.

5.4. Рәсем төсле булырга, А4 яки А3 форматындагы ватман кәгазендә, рәсем ясауның теләсә кайсы техникасы ярдәмендә (акварель, гуаш, төсле карандашлар, акбурлар һ.б.) эшләнелергә тиеш.

5.5. Бәйге өчен иншада хәреф хаталары булмаска тиеш.



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 13 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

5.6. Инша, аңлаешлы почерк белән, юллы дәфтәр битендә (табак бит) язылырга, күп дигәндә өч битле һәм ким дигәндә бер битле булырга яки басма рәвештә (шрифты – Times New Roman, шрифт зурлыгы – 13-14) күп дигәндә 2 битле һәм ким дигәндә 1 битле булырга тиеш.

5.7. Бәйге өчен хезмәтләрне бөкләргә ярамый.

6. Бәяләү критерийләре һәм Бәйгегә йомгак ясау тәртибе

6.1. Бәйге өчен хезмәтләр түбәндәге категорияләр буенча бәяләнә:

| № | “Рәсем” категориясендә хезмәтләрне бәяләү критерийләре | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Рәсем (тематик композиция) эчтәлегенең бирелгән темага туры килүе | 1-5 балл |
| 2 | Хезмәтнең мөстәкыйль эшләнелеше (хезмәт эчтәлегенең бәйгедә катнашучының яшь төркеме үзенчәлекләренә туры килүе) | 1-5 балл |
| 3 | Осталык һәм үзенчәлеклек | 1-5 балл |
| 4 | Теманы ачу | 1-5 балл |
| 5 | Хезмәтнең пөхтәлеге | 1-5 балл |

| № | “Инша” категориясендә хезмәтләрне бәяләү критерийләре | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Теманы ачуның тирәнлеге | 1-5 балл |
| 2 | Эчтәлеге һәм ышандыру дәрәҗәсе | 1-5 балл |
| 3 | Үз фикерен нигезләү | 1-5 балл |
| 4 | Хаталы булу-булмау | 1-5 балл |
| 5 | Башкаларга тиз аңлаешлы булу-булмау | 1-5 балл |
| 6 | Хезмәт эчтәлегенең бәйгедә катнашаучының яшь үзенчәлекләренә туры килүе | 1-5 балл |

6.2. Һәр яшь төркемендә өч призлы урын бирелә.



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 14 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

6.3. Комиссия әгъзалары һәр яшь төр категориясе буенча һәрбер хезмәтне (инша һәм рәсемнәрне – аерым-аерым) биш балл системасы буенча бәяли.

6.4. Иң күп балл җыйган Бәйгедә катнашучыларның хезмәтләре (инша һәм рәсемнәре иң яхшысы дип таныла. Баллар бертигез булган очракта, һәр яшь төркеме буенча җиңүчеләр, ачык тавыш бирү нигезендә, конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән билгеләнә. Тавышлар бертигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы (ул булмаса – комиссия рәисе урынбасарының тавышы) хәлиткеч булып тора.

6.5. Конкурс комиссиясе, конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелеге бәйге өчен хезмәтләргә иң аз балл бирү турында карар кабул иткән очракта яки хезмәтләр Бәйге таләпләренә туры килмәгәндә, Бәйге җиңүчесенең ачыкланмавы турында карар кабул итүгә хокуклы.

7. Бәйге комиссияләре гамәлләренә (гамәл кылмау һәм карарларына шикаять белдерү)

7.1. Ведомство (бәйге) комиссиясе һәм республика комиссиясе карарларына (гамәлләре) Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.04.2015 ел, №4640/15 боерыгына №2 кушымта



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 15 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35

“Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары” дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесенең республика комиссиясе составы

1.А.М.Каюмов – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, рәисе

2.И.В.Андина – Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясенең бүлек начальнигы – баш техник хезмәт инспекторы (үзара килешенеп)

комиссия әгъзалары:

3.М.М.Камалетдинова – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф процессы һәм хезмәтне саклауның матди тәэминат бүлегенең әйдәп баручы белгече

4.М.Е.Алексанов – Татарстан халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләренең республика профсоюз комитеты әйдәп баручы белгече (үзара килешенеп)

5.М.Д.Соколов – Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институтының һөнәри белем бирү стандартлары һәм технологияләре лабораториясе өлкән методисты (үзара килешенеп)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.04.2015 ел, №4640/15 боерыгына №3 кушымта



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 16 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

"Хезмәт һәм укыту-тәрбия эшчәнлеге процессында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары" дигән темага II республика рәсем һәм инша бәйгесенә йомгак ясауга чыгымнар сметасы

| № | Чыгымнар атамасы | Суммасы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Призлар, дипломнар, рамкалар сатып алу | 100000,00 |



Документ создан в электронной форме. № 6446/15 от 05.05.2015. Исполнитель: Камалетдинова М.М.
Страница 17 из 18. Страница создана: 05.05.2015 16:35